ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д. ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**25 ноябрь 2022 ел** **№ 60**

**2018 нче елның 4 нче маендагы Красносельский авыл җирлеге Советының 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 нче елның 17 нче ноябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 28 нче мартындагы 182 нче номерлы карарына «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләренең урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 1015 нче номерлы карары нигезендә, Красносельский авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы,

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 нче елның 4 нче маендыгы 85 нче номерлы карарына (2018 нче елның 24 нче сентябрендәге 96 нчы номерлы, 2020 нче елның 23 нче октябрендәге 4 нче номерлы, 2022 нче елның 26 нчы октябрендәге 55 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- 1 нче пунктның 2 нче абзацында «13274» саннарын «14336» саннарына алыштырырга;
- 2.1 пунктның 2 нче пунктындагы 3 нче абзацында «сигез» сүзен «унбер» сүзенә

алыштырырга;
- 2 нче кушымтада Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башлыгы урынбасарының акчалата бүләкләү күләмнәрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 10 нчы группа |
| Авыл җирлеге Башлыгы урынбасары | 15414 |

- 6 нчы кушымтаның 1 нче «Айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм түләү күләме» пунктында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;
- 11 нче «Муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе» кушымтаның 1 нче пунктындагы 6 нчы пунктчада «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2023 нче елның гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Биектау муниципаль районының рәсми сайтына http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырырга (халыкка җиткерергә)

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов